Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы

Носы төп мәктәбе

# 2021-23 еллар өчен коллектив килешүенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

(Профсоюз утырышы җыелышында чыгыш)

Чыгыш ясаучы: Төхфәтуллина Р.Р

**Февраль 2022**

-Хәерле көн, хөрмәтле профсоюз әгъзалары. 2021 елның 30 апрелендә без 2021-23 еллар өчен коллектив килешүе төзегән идек. Җитди сәбәпләр килеп чыгу сәбәпле аңа үзгәрешләр кертергә туры килде.

1) “Хезмәт килешүендә гарантияләр” разделында 3.1.12 пунктына вакытлыча дистанцион укытуга күчү турында өстәмә кертелде. Бу хөкүмәт органнарыннан хат килгән һәм инфекцион авырулар таралу куркынычын булдырмау һәм Ковид-19 вакцинасын кадаткан очракта каралган.
2) Эш һәм ял вакыты  дип аталучы разделда 4.3.1.пунктына өстәмә кертелде. Әгәр дә эшченең 3 һәм аннан күбрәк 18 яшькә кадәр булган баласы була икән , ул ел саен түләнә торган отпуск ялын иң кечкенә баласына 14 яшь тулганчыга хәтле  үз теләге буенча үзләренә уңайлы булган вакытта алырга хокуклы. (статья 262.2 ТК РФ)
3) 4.7 пункты болай итеп үзгәртелде: 14 яшькә кадәр 2 яки күбрәк баласы булган эшче, 14 яшькә кадәр  баласы булган ялгыз ана, 14 яшькә кадәр  булган, әнисез калган баланы тәрбияләүче ата түләүсез ел саен бирелә торган отпуск ялын үзләренә уңайлы вакытта 14 көнгә кадәр алырга хокуклы. Бу ял  эшченең язмача гаризасы нигезендә еллык түләнә торган ялга өстәлеп, яки аерым яки өлешләп бирелә ала. Ялны икенче эш елына күчерү тыела.
4) 9 разделда 9.1.2. пунктына өстәмә абзац кертелде: “эшче короновирус инфекциясенә (Ковид-19) каршы вакцинация ясаткан очракта аңа 2 көн ял бирергә”
5) “Пенсия белән тәэмин итү” разделының 10.3.1.пунктына өстәмә кертергә: Гомумроссия белем бирү профсоюзының Татарстан республика оешмасының социаль проекты нигезендә пенсиягә (профсоюз әгъзаларының – Татарстан Республикасының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең дәүләтнеке булмаган пенсия тәэминаты) профсоюз бонусын билгеләргә.

Яхшы яңалыклар бу гына түгел. Профсоюз әгъзалары моннан соң санаторийга ял итәргә үзләренең гаилә әгъзаларының берәрсе белән барасы килсә, ул гаилә әгъзасына 20% ташлама булачак. Шулай ук газ өчен түләгән акчаның субсидия өлешен кайтару турында мөрәҗәгать уңай якка хәл ителер дип көтелә.

Чыгышымны тәмамлап шуны әйтәсем килә: безнең районыбыз мәгариф идарәсе профсоюз оешмасы сәламәтлегебезне, эш шартларын яхшырту өстендә бик зур эш алып бара. Без – просоюз әгъзалары үз чиратыбызда ярышларда, үткәрелгән чараларда актив катнашып, сау-сәламәт булып эшләвебезне дәвам итик.